**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
**КАРАР**

«03» апрель 2024 ел Иштирәк авылы № 3

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Иштирәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Таулар авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иштирәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 ноябрендәге 52/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Иштирәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрелендә 14.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Иштирәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт территориясен төзекләндерү (күпфатирлы йортлар территориясен төзекләндерү);

-традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират территориясен койма алу һәм урнаштыру)»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авылында гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт территориясен төзекләндерү (күпфатирлы йортлар территориясен төзекләндерү);

-традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират территориясен койма алу һәм урнаштыру)»

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Иштирәк авыл җирлеге, Иштирәк авылы, Үзәк урам., 116А йорт (Иштирәк авыл мәдәният йорты).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Иштирәк авыл җирлеге Башлыгы Г.С.Гарифуллина